**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 9 декабрендәге 4313 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 1 августындагы 2536 номерлы «Казан шәһәренең Киров районында ачык сервитут билгеләү турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип тану хакында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 48 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте гаризасы нигезендә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 1 августындагы 2536 номерлы «Казан шәһәренең Киров районында ачык сервитут билгеләү турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Казан шәһәре Башкарма комитетының җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**